ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.01.2015 Казан ш. 7-1/т

***Түбән Кама шәһәрендә шәһәр элемтәсендәге гомуми файдаланудагы җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында***

“Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 1995 елның 7 мартындагы №239 нчы санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәрендә шәһәр элемтәсендәге «Горэлектротранспорт» шәһәр унитар предприятиесе (ГУП) тарафыннан башкарылган гомуми файдаланудагы җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь чик тарифларны әлеге карар кушымтасындагыча билгеләргә.

2. **“**Түбән Кама шәһәрендә шәһәр элемтәсендәге гомуми файдаланудагы җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь чик тарифларны билгеләү турында” Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2012 елның 12 июлендәге 7-14/т санлы карарының 1 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына кушымта
23.01.2015 № 7-1/т

## Түбән Кама шәһәрендә шәһәр элемтәсендәге «Горэлектротранспорт» шәһәр унитар предприятиесе (ГУП) тарафыннан башкарылган гомуми файдаланудагы җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь чик тарифлар

| транспорт төре | Бер тапкыр баруга һәм бер урынлы багаж ташуга максималь чик тарифлар (сумда) | | |
|---|---|---|---|
| | транспорт чарасы салонында билет сатып алганда | юл йөргән өчен озак файдаланыштагы билет белән түләгәндә | |
| | | бер тапкыр барган өчен[1] | 50 һәм аннан күбрәк барган өчен [2] |
| Трамвай | 18 | 16 | 12 |

<[1]> шәһәр элемтәсендә юл йөрү өчен билгеле бер сумма чикләрендә транспортта йөрү хокукы бирүче озак файдаланыштагы билет белән түләгәндә;

<[2]> шәһәр элемтәсендә юл йөрү өчен күрсәтелгән срок дәвамында билгеле бер санда транспортта йөрү хокукы бирүче озак файдаланыштагы билет белән түләгәндә.

Искәрмә: Багаж ташу бәясе бару бәясеннән аерым түләнелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының тарифлар буенча карарлар кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге